ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№482 от «16» 05 2016 г.

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2014 елның 22 декабрендәге 1770
номерлы карары белән расланган
2015-2017 елларга Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районында терроризмны һәм
экстремизмны профилактикалау
муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 6.1 өлеше, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы, «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә һәм 2013 елның 26 апрелендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган 2013-2018 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын үтәү буенча илкүләм террорчылыкка каршы комитет тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1.Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 22 декабрендәге 1770 номерлы карары белән расланган 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-Чаралар исеме таблицасына II бүлек өстәргә һәм аны кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. леге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составында Мамадыш муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http:/ mamadysh.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П.Смирновага йөкләргә.

Җитәкче С.М.Гыйморанов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы башкарма комитетының
_____________ 2016 ел, №___
карарына кушымта

| №№ пп | Чара исеме | **башкаручылар** | **Үткәрү вакыты** | **Финанслау мең сумнарда** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2015год** | **2016год** | **2017год** |
| **II 2013 елның 26 апрелендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган 2013-2018 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планы чаралары** | | | | | | |
| 33 | Квалификацияле белгечләр (коллективлар) сайлап алуны оештырырга, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә террорчылык идеологиясе йогынтысына иң бирелүчән яки инде эләккән кешеләр категориясенә адреслы профилактик йогынты ясау буенча даими эшләүчеләр (яшьләр; чит илдә дини, күбесенчә ислам белеме алган кешеләр; террорчылык өчен җәзасын үтәгән җинаятьчеләр (экстремистик) эшчәнлеге, подполье әгъзаларының туганнары) | муниципаль районның террорчылыкка каршы комиссиясе, , район буенча МВД РФ бүлеге | 2016 ел һәм алга таба даими | | | |
| 34 | Интернет челтәренең район мәгълүмат ресурсларында социаль челтәрләрдә һәм блогларда террорчылыкка каршы эчтәлектәге мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны әзерләү һәм урнаштыруны тәэмин итәргә | муниципаль районның террорчылыкка каршы комиссиясе, җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтәләр секторы | квартал саен | | | |
| 35 | Кинопрокат системасын террорчылыкка һәм экстремизмга каршы юнәлештәге документаль һәм нәфис фильмнар (шул исәптән видеофильмнар) таратуда кулланырга | Мәдәният бүлеге | 2016 ел һәм алга таба даими | | | |
| 36 | Милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән мәдәни-агарту чараларын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, ОДМС | квартал саен | | | |
| 37 | Кинофильмнарны системалы рәвештә күрсәтү, халык иҗаты коллективларының чыгышларын оештыру, | Мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | спектакльләр күрсәтү, күргәзмәләр, түгәрәк өстәлләр, «терроризмга каршы торуның мөһим фактлары буларак халыкара хезмәттәшлекне ныгыту»темасына семинарлар үткәрү | | квартал саен | | | |
| 38 | Яшьләрне рухи һәм патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән Халык иҗаты өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү | Мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, ОДМС, | квартал саен | | | |
| 39 | Терроризмга каршы тору өлкәсендә җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү өчен социологик тикшеренүләр үткәрүне оештыру. | муниципаль районның террорчылыкка каршы комиссиясе,, җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтәләр секторы | Елга бер тапкыр | | | |
| 40 | Тормыш уңышының нигезе һәм терроризм һәм экстремизмны профилактикалауның мөһим алшарты буларак шәхси иҗади хезмәткә юнәлдерелгән патриотик карашлы һәм физик яктан үсеш алган яшь буынны тәрбияләүгә юнәлдерелгән чараларны күздә тоткан планнар һәм программалар эшләү (гамәлдәге планнарга төзәтмәләр кертү) | Мәдәният бүлеге, мәгариф бүлеге, ОДМС | 2016 ел | | | |
| 41 | Яшьләрне гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбияләү өлкәсендә эш алып баручы яшьләр берләшмәләре эшчәнлеген мониторинглау | ОДМС | Ел саен | | | |
| 42 | Террор һәм экстремистик юнәлештәге җинаятьләр өчен җәзаны үтәгән гражданнарны социаль реабилитацияләү буенча чаралар үткәрү | муниципаль районның террорчылыкка каршы комиссиясе, МВД РФ бүлге, иҗтимагый оешмалар | кирәк булганда | | | |
| 43 | Мәгариф учреждениеләрендә терроризм идеологиясенең җинаятьчел асылын ачучы эшләнгән уку материалларын уку процессына кертү | мәгариф бүлеге, | 2017 ел | | | |

**Җитәкче урынбасары** А.П.Смирнова